## 1. <u>Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре.</u>

Сыйныф: *8 “Б”*
Укытучы: *Васильева А.В*
Уку планы буенча
Татар теленнән: *70 сәг.*
Атнага: *2 сәг.*
Дәреслек
Р.З.Хәйдәрова,Р.Л.Малафеева.Татар теле,8 сыйныф,Казан, “Татармультфильм” нәшрияты, 2015 ел.
Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

**Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:**

1. Программа: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, 2014 ел.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында башлангыч гомуми белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2018-2019 уку елына укыту планы (№__ педсовет протоколы, ____________________2018 ел).

Төп гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар теле укыту түбәндәге **максатларга** юнәлтелгән:

– татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру: укучыларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләрен филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җиткерү; укучылар нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатыннан мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнү;

– коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;

– “Татар теле” предметына карата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру, һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштерүгә шартлар тудыру;

– төп гомуми белем бирү баскычын төгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата дөньякүләм кабул ителгән шәхси кыйммәтләрне формалаштыру**.**

## 1. Укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре

Күрсәтелгән максатлар нигезендә татар теле **укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре** билгеләнде.

Укытуның **шәхескә кагылышлы нәтиҗәләре:**

– укучыларда күпмилләтле җирлектә яшәүче халыкларга карата ихтирамлык, гражданлык бердәйлеге хисләре формалаштыру; милли үзаң һәм башка милләт культураларына карата толерантлы караш булдыру;

– *туган җир, Ватан* төшенчәләре, үз культураң аша дөнья культурасына карата ихтирам тәрбияләү, аны өйрәнү теләге формалаштыру;

– шәхеснең үз-үзен актуальләштерү шарты буларак, аның мөстәкыйльлеген һәм җаваплылыгын үстерү;

– әйләнә-тирәдәге кешеләргә карата игелеклелек, ышаныч һәм игътибарлылык, ярдәм күрсәтүгә әзерлек, ихтирам, әңгәмәдәшне тыңлый һәм ишетә белү, кешеләрнең үз фикеренә хокукын таный белү нигезендә аралашу һәм хезмәттәшлек итү өчен, психологик шартлар формалаштыру;

– үзлегеңнең белемеңне арттыру һәм үз-үзеңне тәрбияләү нигезендә, үз эшчәнлегеңне оештыра алу осталыгын формалаштыру;

– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;

– әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирә белү;

– *гаилә, туган ил, мәрхәмәтлелек* төшенчәләрен кабул итү, башкаларга карата *түземлелек, кайгыртучанлык, кеше кадерен белү* кебек хисләр формалашкан булу.

Укытуның **метапредмет нәтиҗәләре**

Төп белем бирү баскычында татар теле, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

***Танып белү нәтиҗәләре:***

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;

– иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм төзи белү;

– объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгели белү;

– төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;

– тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллана белү.

***Регулятив нәтиҗәләр*:**

– уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;

– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;

– уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;

– билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;

– укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;

– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләр формалашу.

***Коммуникатив* нәтиҗәләр:**

– әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;

– әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзи белү;

– аралашучанлык, хисләлек, эмпатия хисләре формалашу;

– парларда һәм күмәк эшли белү;

– мәгълүматны туплау өчен, күмәк эшли белү;

– әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

Укытуның **предмет нәтиҗәләре**

Укучының төп гомуми белем бирү мәктәбен тәмамлаганда, **сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча түбәндәге предмет нәтиҗәләренә ия булуы** планлаштырыла:

***диалогик сөйләм:***

- *стандарт ситуацияләрдә сөйләмне башлый, дәвам итә, төгәлли белү;*
- *парлап яки күмәк сөйләшү барышында, үз фикереңне аңлата,раслый, дәлилли белү, ситуация* аңлашылмаганда, сорау биреп ачыклау;
- вакыйганы ачыклау максатыннан сораштыру;
- риза булмау, үтенечне кире кагу;
- бергә эшләргә тәкъдим итү.

***монологик сөйләм:***

- кереш, эндәш сүзләрне кулланып, орфоэпик һәм грамматик нормаларны саклап, үз фикереңне төгәл җиткерү;
- укыганның, ишеткәннең төп эчтәлеген җиткерә белү, үз мөнәсәбәтеңне белдерү;
- сораулар ярдәмендә, план буенча яисә мөстәкыйль рәвештә өйрәнгән текстны үз сүзләрең белән сөйләү;
- текстны дәвам итеп, үзгәртеп сөйләү;
- программада тәкъдим ителгән темалар буенча тиешле эзлеклелектә сөйләү;

– төрле вакыйгалар, яңалыклар турында хәбәр итү;
– персонажларны тасвирлау.

***тыңлап аңлау:***

– сүзләрне, җөмләләрне тулысынча яки өлешчә тыңлап аңлау;
– сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлату, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнашу;
– тәкъдим ителгән текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорау җөмләләр төзү, сорауларга җавап бирү;
– зур булмаган аутентив яки адаптацияләнгән әдәби әсәрләрдән өзекләрне, мәгълүмати характердагы текстларны, вакытлы матбугат язмаларын аңлап, эчтәлеге буенча фикереңне әйтү.

***уку:***

– татар теленең әйтелеш нормаларын саклап, сәнгатьле һәм аңлап уку;
– текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлау;
– күрмә-символик мәгълүматлы, иллюстрацияле, таблицалы текстлар белән эшләү күнекмәләренә ия булу;
– текст укыганда, кирәкле мәгълүматны аерып алу, системага салу, чагыштыру, анализлау, гомумиләштерү, интерпретацияләү һәм үзгәртү кебек эшчәнлекләрне үзләштерү;
– текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлау.

***язу:***

– өйрәнелгән темалар буенча актив кулланылышта булган сүзләрне дөрес язу;
– конкрет бер тема буенча хикәя төзеп язу;
– прагматик текстлар (рецептлар, белдерүләр, афиша һ.б.), эпистоляр жанр текстларын (шәхси һәм рәсми хатлар, котлаулар һ.б.) төзеп язу;
– үзеңне борчыган проблемага карата фикерләреңне язмача җиткерү;
– тәкъдим ителгән текстның эчтәлегенә нигезләнеп, аны үзгәртеп яки дәвам итеп язу.

**2.Эш программасының эчтәлеге.**

| Аралашу темалары | Дәресләр саны | Укчыларныңбелемдәрәҗәләрекүрсәткечләре |
|---|---|---|
| Күп укыган - күп белер. | | Класташларыңның белем алуга карашын, яхшы уку өчен кирәкле сыйфатлар турында сөйли белү. Яхшы укуга карата мөнәсәбәтнеңне белдерә белү.<br>Хикәя фигыльнең заман формаларын (хәзерге, үткән, киләчәк) сөйләмдә куллануны ныгыту. Кушма исем һәм кушма фигыль хәбәрләрне билгеләргә күнектерү. |
| Мин һәм минем яшьтәшләрем | | Яшьтәшләрең белән аралашу кагыйдәләре, дуслашу серләре, нинди кызлар һәм малайлар ошавы турында сөйләшү. Тәрҗемәле, антонимнар, синонимнар, фразеологик һәм башка төр сүзлекләрдән файдаланырга күнектерү. |
| Табигать һәм кеше. | | Табигать төшенчәсе, бүгенге экологик проблемалар, табигатькә сак караш турында сөйләшү.<br>Модаль кисәкләр турында төшенчә бирү. Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне сөйләмдә куллану. Татар җөмләсендәге сүз тәртибен өйрәнү. Бәйлек һәм бәйлек сүзләрне сөйләмдә куллану. Билгеләү, билгесезлек, юклык, тартым алмашлыкларының сөйләмдә еш кулланыла торган очраклары белән таныштыру |
| Туган җирем – Татарстан | | Татарстанның табигате турында мәгълүмат бирә белү. Казан шәһәре, андагы яңа үзгәрешләр турында сөйли белү. Казан шәһәрендәге спорт корылмалары, ял итү урыннары, тарихи истәлекләр турында әңгәмәгә керә белү. Хәл фигыльне сөйләмдә куллану. Аларның төрләрен аера белү. |

## 3. Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру

| № | Тема | Уку эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Белем бәйрәме белән котлау. | Рәсем буенча әңгәмә. | 4.09 | |
| 2 | Мәктәбем. Монологик сөйләм. | Укытучыларны, иптәшләреңне Белем көне белән котлый белү | 7.09 | |
| 3 | Атна көннәре.. | Тартымлы исем-нәрне сөйләмдә дөрес куллану. “Мәктәбем” шигы-рен сәнгатьле уку, мәктәбең турында сөйли белү. | 11.09 | |
| 4 | Мин җәйне ничек үткәрдем? | Атна көннәре атамаларын кулланып, нишләгәнеңне, нишләячәгеңне, расписание буенча нинди фәннәр керәчәген сөйли белү. | 14.09 | |
| 5 | Кереш контроль эш. | Хикәя фигыльнең заман формаларынидөрес кулланып, беренче сентябрь турында сөйли белү. | 18.09 | |
| 6 | Диалогик сөйләм "Җәйге ял" ” | Шигырь эчтәлеге буенча сөйләш, фикер алышу | 21.09 | |
| 7 | "Өлгерәм әле..." тексты өстендә эш. | Текст буенча эшләү | 25.09 | |
| 8 | “Өлгерәм әле...” тексты өстендә эш. | Тексттагы лексик-грамматик материалны истә калдыру. Текстны аңлап уку, кирәкле мәгълүматны таба белү. | 28.09 | |
| 9 | Без хикәя язабыз | “Өлгерәм әле...” хикәясен үзгәртеп язу. Р.Валиеваның “Барый телевизор карый” шигырендәге герой белән чагыштырып сөйли белү. | 2.10 | |
| 10 | Инфинитив темасына караган лексика | Яңа лексика өйрәнү | 5.10 | |
| 11 | Ситуатив күнегүләр | Ситуатив күнегүләр | 9.10 | |
| 12 | “Өлгерәм әле...” тексты өстендә эш (дәвамы) | “Өлгерәм әле...” тексты өстендә эш (дәвамы). Дилоглар төзү. | 12.10 | |
| 13 | Р.Вәлиев “Барый телевизор карый” | Уку, сорауларга җавап бирү | 16.10 | |
| 14 | Мәкальләр. | Мәкальләрне уку, тәрҗемә эше | 19.10 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 15 | Мин һәм минем яшьтәшләрем | Яшьтәшләр турында сөйләү | 23.10 | |
| 16 | Контроль эш | Укучыларның белемнәрен тикшерү. | 26.10 | |
| 17 | Хаталар өстендә эш. Хат | Дусларның тышкы һәм характер сыйфатларын сурәтләп сөйли белергә өйрәнү | 30.10 | |
| 18 | Аралашу серләре | Сөйләмдә һәм язуда сыйфатларны куллана белү. | 9.11 | |
| 19 | Дуслашу серләре | Дусларның тышкы һәм характер сыйфатларын сурәтләп сөйли белергә өйрәнү. | 13.11 | |
| 20 | “Аралашу серләре” тексты | “Аралашу серләре” текстын аңлап уку; хат авторының сораулары буенча фикер алышуда катнашу; фикер белдергәндә, кереш сүзләр куллану | 16.11 | |
| 21 | Аралашу темасына диалогик сөйләм | Аралашу серләре” текстын аңлап уку; хат авторының сораулары буенча фикер алышуда катнашу; фикер белдергәндә, кереш сүзләр куллану | 20.11 | |
| 22 | “Җиңәсем килде” хикәясе өстендә эш | Сәнгатьле уку, сорауларга җавап бирү | 23.11 | |
| 23 | “Җиңәсем килде” хикәясе өстендә эш. Диалогик сөйләм | Парлап эшләү, диалоглар төзү | 27.11 | |
| 24 | “Ал кирәк, гөл кирәк, безгә нинди кыз кирәк” | Яшьтәшләрең белән аралашу кагыйдәләре, дуслашу серләре, нинди кызлар һәм малайлар ошавы турында сөйләшү. | 30.11 | |
| 25 | “Ал кирәк, гөл кирәк, безгә нинди кыз кирәк”тексты буенч биремнәр | Дуслашу серләре, нинди кызлар һәм малайлар ошавы турында сөйләшү. | 4.12 | |
| 26 | “Мин төс яшел, ә синеке? | Төсләр өрәнү | 7.12 | |
| 27 | Төсләр өйрәнү | Төсләр өрәнү | 11.12 | |
| 28 | Бсү.” Музыка дөньясында” тексты буенча эш | Яраткан музыка турында сөйли белү | 14.12 | |
| 29 | Контроль эш | Контроль эш | 18.12 | |
| 30 | Хаталар өстендә эш | Хаталар өстендә эш | 21.12 | |
| 31 | Кабатлау | Кабатлау | 25.12 | |
| 32 | Табигать һәм кеше | Табигать төшенчәсе, бүгенге экологик проблемалар, табигатькә сак караш турында сөйләшү. | 11.01 | |
| 33 | Табигать төшенчәсе | Табигать төшенчәсе, бүгенге | 15.01 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | экологик проблемалар, табигатькә сак караш турында сөйләшү. | | |
| 34 | Экологик проблемалар | Бүгенге экологик проблемалар, табигатькә сак караш турында сөйләшү. | 18.01 | |
| 35 | Табигать байлыгы. | Табигать байлыгы, табигатьтәге кызыклы күренешләр турында мәгълүмат бирә белү | 22.01 | |
| 36 | Урман – кешенең якын дусты | Урман – кешенең якын дустытемасына сөйләшү | 25.01 | |
| 37 | Табигать һәм без, табигатьтәге кызыклы күренешләр | Яңа лексика белән танышу, рәсемнәр буенча сөйләшү | 29.01 | |
| 38 | Ел фассыллары | Уку, эчтәлеге буенча фикер алышу, мәкальләр уку, рәсемнәр күзәтү. Төрле биремнәр эшләү | 1.02 | |
| 39 | Табигать һәм без тексты буенча эш | Тема буенча укытучының кереш сүзе, текстны укып, әңгәмә оештыру. | 5.02 | |
| 40 | Кошлар | Тема буенча укытучының кереш сүзе, текстны укып, әңгәмә оештыру. | 8.02 | |
| 41 | Сүзле, мавыктыргыч уеннар | Сүзле, мавыктыргыч уеннар | 12.02 | |
| 42 | БСҮ Диалоглар. Ребуслар чишү | БСҮ Диалоглар. Ребуслар чишү | 15.02 | |
| 43 | Туган җирем-Татарстан | Уку, эчтәлеге буенча фикер алышу, мәкальләр уку, рәсемнәр күзәтү. Төрле биремнәр эшләү | 19.02 | |
| 44 | И.Юзеев “Татарстаным” шигыре | Шигырьне уку, сорау-биремнәргә җавап эзләү. | 22.02 | |
| 45 | Татарстанның хайваннар, кошлар дөньясы | Кошлар турында сөйләшү | 26.02 | |
| 46 | Татарстанның башкаласы Казан, аның бүгенге йөзе: | Хикәяне уку, сүзләрне аңлату, сораулар буенча төп фикерне табу, нәтиҗә ясау | 1.03 | |
| 47 | Казан - музейлар шәһәре | Уку, эчтәлеге буенча фикер алышу, мәкальләр уку, рәсемнәр күзәтү. Төрле биремнәр эшләү | 5.03 | |
| 48 | Казан-бөек шәхесләр шәһәре. | Әңгәмә, сәнгатьле уку | 8.03 | |
| 49 | Казан-спорт шәһәре | Әңгәмә, сәнгатьле уку. Рәсемнәр | 12.03 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | буенча эш | | |
| 50 | Казан –кунакчыл шәһәр | Текст буенча фикер алышу | 15.03 | |
| 51 | Сөембикә манарасы | Укыганны анализлый белү, үз фикереңне тексттан дәлилләр табып исбатларга өйрәнү, белемнәрне тикшерү. | 19.03 | |
| 52 | Казанның тарихи урыннары | Рәсемнәр буенча эш. | 22.03 | |
| 53 | Казанның тарихи урыннары | Тәрҗемә итү. Текстка таянып сөйләү. | 2.04 | |
| 54 | Казан-зур промышленность шәһәре | Казан шәһәре турында сөйләү | 5.04 | |
| 55 | Диалогик сөйләм телен үстерү дәресе | Эчтәлеге буенча фикер алышу, сорауларга җавап бирү | 9.04 | |
| 56 | Монологик сөйләм телен үстерү дәресе | Парлап эшләү, сәнгатьле уку. | 12.04 | |
| 57 | Сүзле уеннар | Сүзле уеннар | 16.04 | |
| 58 | Табышмаклар һәм мәкальләр | Табышмаклар һәм мәкальләр чишү | 19.04 | |
| 59 | Проект эше | Проект яклау | 23.04 | |
| 60 | Тәрҗемә итү күнегүләре | Тәрҗемә итү. Текстка таянып сөйләү. | 26.04 | |
| 61 | Ситуатив күнегүләр | Ситуатив күнегүләр | 30.04 | |
| 62 | Урманның файдасы | Урманның файдасы турында сөйләшү | 3.05 | |
| 63 | Урман нәрсәгә һәм нәрсә белән файдалы | Тема буенча укытучының кереш сүзе, текстны укып, әңгәмә оештыру. | 7.05 | |
| 64 | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү дәресе | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү дәресе | 10.05 | |
| 65 | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү дәресе | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү дәресе | 14.05 | |
| 66 | Еллык контроль эш | Еллык контроль эш | 17.05 | |
| 67 | Хаталар өстендә эш | Хаталар өстендә эш | 21.05 | |
| 68 | Йомгаклап кабатлау | Йомгаклап кабатлау | 24.05 | |
| 69 | Йомгаклап кабатлау | Йомгаклап кабатлау | 28.05 | |
| 70 | Йомгаклап кабатлау | Йомгаклап кабатлау | 31.05 | |